**Тема : «Укучыларның индивидуаль сәләтен ачуда иҗади биремнәрне куллану.» (доклад)**

Безнең чор фән һәм техника прогрессының бик зур темплар белән алга киткән чоры. Айлап, көнләп, хәтта сәгатьләп яңа ачышлар ясалып тора: цифрлы технологияләр , кеше баш миенең интельлектуаль фикерләү сәләтен өлешчә модельләштерә торган технологияләр. Әлбәттә, прогресс иҗаттан башка мөмкин түгел. Мәктәпләрдә моңа кадәр булган бертөрле алгоритмнар белән эшли торган методикага күбрәк урын бирелә иде. Мәктәпнең кече яшьтәге балаларда була торган фонтастикасы, хыялга бирелүе, үзенчә эшләргә теләвен еш кына мәктәп үстерми иде. 1999 елгы«Начальная школа» журналының №1 санында педагогик тәҗрибә Центры методисты В.А. Степихова мисал итеп китергән вакыйга тукталып үтәсе килә:

«Однажды маленький мальчик отправился в школу.
Это был совсем ещё маленький мальчик,
А школа была большая.
Но когда маленький мальчик понял,
Что можно попасть в класс прямо через дверь во дворе,
Он почувствовал себя довольным, а школа не выглядела такой большой,
Однажды утром , когда мальчик пробыл
в школе уже некоторое время,
Учительница сказала: «Сегодня мы будем рисовать!»
Он любил рисовать. Он любил различные рисунки:
Львов и тигров, кур и коров, поездов и кораблей,
И он взял свою коробку карандашей и начал рисовать,
Но учительница сказала: «Подождите, ещё не время начинать!»
И она ждала до тех пор, пока все не приготовились.
«Теперь ,- сказала учительница, -мы будем рисовать цветы.» «Здорово!»- воскликнул маленький мальчик.
Он любил рисовать цветы.
И он начал рисовать великолепные цветы.
Розовым, оранжевым и синим карандашом.
Но учительница сказала: « Подождите я вам покажу, как надо делать.»
И она нарисовала красный цветок с зелёным стебельком.
«Вот,- сказала учительница, - теперь вы можете начинать.»
Маленький мальчик посмотрел на цветок, нарисованный учительницей. Затем он посмотрел на свои цветы.
Ему больше нравились свои цветы.
Но он этого не сказал.
Он просто перевернул листок и нарисовал
цветок такой,как у учительницы:
Он был красным с зелёным стебельком.
В следующей раз он самостоятельно открыл дверь.
Учительница сказала: «Сегодня мы будем заниматься лепкой!»
«Хорошо!»- подумал мальчик, он любил лепку.
Он умел делать различные штучки из глины:

Змей, снеговиков, слонов и мышей, машины и грузовики.
Он начал разминать свой кусочек глины.
Но учительница сказала: «Подождите, ещё не время начинать!»
И она ждала до тех пор, пока все приготовились.
«Теперь ,- сказала учительница, - мы будем делать блюдо»
«Здорово!»- подумал маленький мальчик . Он любил делать блюда.
И он начал их лепить: всевозможных форм и размеров.
Тогда учительница сказала: «Подождите! *Я* покажу вам, как делать!»
И она всем показала, как сделать большое глубокое блюдо.
«Вот,- произнесла учительница,- теперь можете начинать.»
И маленький мальчик сделал такое блюдо.
По родители мальчика переехали , и ему пришлось также поменять школу.
Эта школа была ещё больше, чем прежняя.
В ней не было двери, ведущей с улицы прямо в класс.
Он должен был подняться по большим ступенькам И пройти по длинному коридору, чтобы подойти к классу.
В первый день учительница сказала: «Сегодня мы будем рисовать.» «Ура!»- подумал маленький мальчик .
И начал ждать , когда учительница скажет как делать.
Но учительница ничего не сказала,
Она просто прогуливалась по классу.
Когда она подошла к маленькому мальчику, она сказала:
«Ты не хочешь рисовать?»
«Хочу ,- ответил мальчик. А что нужно рисовать?»
*«Я* не знаю пока ты этого не нарисуешь»,- сказала учительница.
«А как я буду рисовать?»- спросил мальчик .
«Как хочешь»- сказала учительница .
«И не важно, каким цветом?- спросил маленький мальчик.
«Не важно каким цветом,- ответила учительница .- Если бы все сделали один рисунок ,
Как бы я узнала , кто что нарисовал и чей это рисунок?»
«Я не знаю»,- сказал маленький мальчик.»
И он начал рисовать красный цветок на зелёном стебле.

Әгәрдә уйлап карасак, укучыга «яшел сабакта кызыл чәчәк ясавын» без дә таләп иттек. Дәреслектәге шул ук биремнәр, шул ук сочинениеләр, шул ук изложениеләр , шул ук күнегүләр...Дәрескә карата кызыксыну югала гына... Ә укучыга ничек булышырга, ничек аның иҗади сәләтен, мөмкинлеген ачарга?!

Билгеле булганча, кешенең иҗат эше белән турыдан-туры идарә итәргә ярамый, ул вакытка бәйле рәвештә гомуми эшчәнлек нәтиҗәсендә туа. Бу эшчәнлек башкалар өчен кызыклы булган очракта , тагын да зур үсеш алырга мөмкин, эгәрдэ һәр укучы үзенең белем-күнекмәләрен, иҗади фикерләрен реальләштерә белсә.

Үземнең эш дәверендә нәкъ менә иҗади шәхес тәрбияләү максатыннан укучыларның индивидуаль иҗади фикерләү сәләтен үстерү юнәлешендә төрле алымнар кулланып карыйм.

Мәсәлән, татар теле һәм әдәби уку дәресләрендә укучыларны иҗади эшкә тарту

аеруча җайлы . Укылган әсәр эчтәлеге буенча рәсемнәр ясау, иллюстрацияләр ясап алып килү кебек эшләр , аны яклау, иҗади фикерләрен уртаклашу- укучыларны бик җанландырды , чөнки җәнлекләрне алар аеруча яраталар.

Сочинениеләр язу да- укучының үз фикерен язмада чагылдыра алуга зур этәргеч булып тора. Мәсәлән, «Минем беренче укытучым», «Хезмәт иясе-хөрмәт иясе», «Минем яраткан ел фасылым», «Яңа мәктәп» кебек темаларга багышланган сочинениеләр укучының эчке дөньясын, әйләнә-тирә мохиткә карашын ачыкларга ярдәм итә. һәр укучы үз мөмкинлегеннән чыгып иҗади «ярыша». Укытучы көткән нәтиҗә югары дәрәҗәдә булмаса да , ул аны зур сабырлык белән көтеп, укучыны үсендерергә, мактарга тиеш. Шул очракта гына укучыдан көткән нәтиҗәне өлешчә алырга мөмкин.

Иҗади фикерләү күп вакыт сарыф итүне сорый, ләкин аны үзагымына куярга ярамый, чөнки кызыксынучанлык, яңалыкка омтылу , мөстәкыйльлек кебек сыйфатлар балачакта формалаша. Ярыш рәвешендәге дәресләр (интеллектуаль турнир, дәрес-викторина , уйлап табучылар конкурсы) уңышлы һәм кызыклы үтә. Ә чикләнгән дәрес кысаларында мондый эшне башкарып чыгып булмый һәм укучыларны материалны ятлау, сөйләү кабатлау кебек эшләр канәгатьләндерми. Алар мөстәкыйль эзләнергә, җаваплар табарга тели. Шуңа күрә, иҗади сәләтне үстерүне сыйныфтан тыш чаралар вакытында эшкә җигәргә мөмкин . Укучылар бик теләп сәхнә әсәрләрен уйнарга яраталар.Аларга рольләр бүлеп бирелә һәм сәхнә киемнәрен хәзерләү, декорацияләр укучының үз карамагына тапшырыла, ә үзенә йөкләнгән эшне җиренә җиткереп эшләү - башлангыч сыйныф укучысына хас сыйфат.

Шулай ук, тәнәфес вакыты, озайтылган көн группасы, төрле конкурслар, җәйге лагерь вакытлары- укучыларны мондый иҗади эшчәнлеккә тартырга бик кулай вакыт.Аппликация, пластилин белән эшләү укучыларның фикерләү сәләтен генә арттырмый, ә кул чукларының җитез эләү күнекмәләренә дә тәэсиренә зур. Интеллектуаль уеннар үткәрү дә зур ярдәмгә килә.Укучылар түбәндәге уеннарда бик теләп катнашалар:

«Ялгыш укытучы»( укытучы яки укучы текстны укыганда хата җибәрә , укучылар төзәтә.) «Нинди предмет уйланган?» (уенны оештыручы бер предмет турында уйлый.Уенда катнашучылар сораулар бирәләр, ләкин «әйе» яки «юк» дип кенә җавап алалар)

Димәк, укучының кечкенә күләмле генә булса да иҗади эшен күрә белү, аны бәяләү -укытучының иң зур хезмәте. Шуның аша укучыга үз-үзенә ышанырга, сынап карарга, сәләтен ачарга мөмкинлек бирергә.һәм укытучы да яңадан-яңа алымнар белән укучыны алга этәрергә тиеш.

Хәзер Мәгариф системасы алдында инновацион программалар кертү мәгарифне мәгълүматлаштыру , югары квалификацияле эшче кадрлар хәзерләүгә зур игътибар нык арттырыла. Безнең бурыч - үсеп килүче яшь буынга катлаулы конкуренция шартларында тормышта үз урынын, үз һөнәрен табу өчен иҗади мөмкинлекләрен тормышка ашыра торган шәхесләр тәрбияләү.